ГЛАВА ТОЙГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТОЙГУҖА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

переулок Школьный, дом 7, деревня Тойгузино,
Менделеевский район, Республика Татарстан, 423646

Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт, Тойгуҗа авылы,
Менделеев районы, Татарстан Республикасы, 423646

Тел. (факс): 8(85549) 3-40-13 e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08 ноябрь 2019 ел № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Менделеевск муниципаль районының
Тойгуҗа авыл җирлегенең Рус Сарсазы авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезндә КАРАР ИТӘМ:

1. 2019 елның 24 ноябрендә 12.00 сәгатькә Тойгуҗа авыл җирлегенең Рус Сарсазы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен үткәрү урыны итеп: Рус Сарсазы авылы, Лесная ур., 6а йортын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2019 нчы елда Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең Рус Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку бүлегендәге студентлардан тыш, һәм алынган акчаларны киләсе эшне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән ризалашасызмы?:

- Рус Сарсазы авылы юлларын кардан чистарту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгән көннән соң 3 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тойгуҗа авыл җирлеге Башлыгы                                                    Сафин Р.А.